**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КРУГЛОЕ ПОЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

20 май 2020 ел № 62/2

**Круглое Поле авыл җирлеге Советының 2015 елның 27 апрелендәге 54/1 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен сайлау округлары схемасын төгәлләштерү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 25 статьясы нигезендә, авыл җирлеге территориясенең алга таба үсеше, яңа урамнар барлыкка килү һәм яңа йортларны файдалануга кертү белән бәйле рәвештә, округларның расланган чикләрендә бермандатлы сайлау округларының гамәлдәге схемасын төгәлләштерү максатында, Круглое Поле авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Бермандатлы сайлау округлары тасвирламасын түбәндәгеләрне кертеп төгәлләштерергә (Круглое Поле авыл җирлеге Советының 2015 елның 27 апрелендәге 54/1 номерлы карарына кушымта):

1.1. Круглое Поле 1 нче бермандатлы сайлау округына: Радужная ур., Раздольная ур.;

1.2. Круглое Поле 10 нчы бермандатлы сайлау округына: Марат Фәйзуллин ур., Цветочная ур., Парковая ур.

2. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга һәм Круглое Поле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Э.Р. Низамиева

Круглое Поле авыл җирлеге Советының 2020 елның 20 май 62/2 номерлы карарына кушымта

# Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Круглое Поле авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен сайлау округлары схемасының график сурәте

